**Эшне башкару өчен кулланма**

Татар теленнән белем һәм күнекмәләрне тикшерү өчен биремнәрне башкаруга 45 минут вакыт бирелә. Тәкъдим ителгән эш 2 өлештән тора.

Беренче өлеш 20 биремне үз эченә ала (A1-A20), сез алар арасыннан дөрес дип уйлаган җавапны сайлап алырга тиеш.

Икенче өлеш B1-B6 биремнәреннән тора. Әлеге биремнәр текстка бәйле рәвештә башкарыла. B1-B6 биремнәренә җавапны сез мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга һәм язып куярга тиеш.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәгез. Аларны үтәү барышында сезнең өчен кыенлык тудырганнары килеп чыкса, әлеге биремне калдырып торып, алдагыларына күчәргә киңәш итәбез. Сез бу биремнәргә, вакытыгыз калган очракта, кабат әйләнеп кайта алачаксыз. Беренче өлештәге биремнәргә якынча 1,5 минут вакыт бирелә. Икенче өлештәге һәр биремгә 2 минут вакытыгызны сарыф итегез.

Дөрес җаваплар, катлаулылыкларыннан чыгып, 1 яки югарырак баллар белән бәяләнәләр. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, сезгә гомуми балл чыгарыла, шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җаваплар бирергә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез !**

**2 вариант**
**1 өлеш (А)**

***Әлеге өлештәге биремнәрне (А1-А20) үтәгәндә, җавалар бланкында эшләнә торган бирем аста урнашкан, дөрес дип табылган җавап номеры шакмагына «Х» билгесе куегыз.***

**А1. Бер генә иҗектән торган сүзне табыгыз.**

1. чәчәк
2. җимеш
3. күз
4. мәктәп

**А2. Кайсы рәттәге сүзләрдә [къ] авазы әйтелә?**

1. күлмәк, чәчәк, көн, китап
2. конфет, вокзал, пешекче, кибетче
3. карга, ак, акрын, коена
4. каражимеш, күчтәнәч,төнбоек, костюм

**А3. Кайсы сүздә ь хәрефе аеру билгесе булып тора?**

1. төньяк
2. сәгать
3. яшь
4. шәфкать

**А4. Хаталы сүз булган рәтне табыгыз.**

1. зирәк, хат, җиләк, маңгай
2. волейбол, завод, пароход, витамин
3. дингез, кибет, ябалак
4. яшьлек, тиен, һәм

**А5. Татар телендә генә булган сузыклар рәтен табыгыз.**

1. [ә], [ө],[ү]
2. [а], [о], [у]
3. [и], [о], [ы]
4. [ы], [э/е], [и]

**А6. Иҗекләргә дөрес бүленгән сүзләр рәтен билгеләгез.**

1. си-шәм-бе, Ка-зан, ур-ман
2. баб-ай, дәр-ес, мәк-тәп
3. кың-гы-р-ау, мо-ң-су, а-га-ч-лар
4. кү-лмәк, чү-лмәк, нәт-иҗә

**А7. Мәгънәләре ягыннан охшаш сүзләрне кайсы сүзлектә табып була?**

1. орфографик сүзлек
2. аңлатмалы сүзлек
3. синонимнар сүзлеге
4. татарча-русча сүзлек

**А8. Фигыльләрнең төркемчәсен билгеләгез.**

*тырышса, кайгырса*

1. хикәя фигыль
2. шарт фигыль
3. боерык фигыль
4. үткән заман хикәя фигыль

**А9. Ялгызлык исемнәренең төп аермасы-**

1. һәрвакыт баш хәреф белән языла
2. хайваннарга бирелә торган кушаматлар керми
3. авыл исемнәре керми
4. кеше исемнәре керми

**А10.** *Бик, иң* **сүзләре белән ясала торган сыйфат дәрәҗәсен билгеләгез.**

1. гади дәрәҗәдә
2. кимлек дәрәҗәсе
3. чагыштыру дәрәҗәсе
4. артыклык дәрәҗәсе

**А11.** *Синнән* **зат алмашлыгының килешен билгеләгез.**

1. иялек килешендә
2. урын-вакыт килешендә
3. юнәлеш килешендә
4. чыгыш килешендә

**А12. Төшеп калган сүзне табыгыз.**

*“... предметны белдерәләр. Алар кем? нәрсә?” соравына җавап бирәләр.*

1. фигыльләр
2. исемнәр
3. хәбәрләр
4. сыйфатлар

**А13.** *Бер...юлы* **сүзендә төшеп калган хәрефне билгеләгез.**

1. ү хәрефе
2. ь билгесе
3. ъ билгесе
4. р хәрефе

**А14. Парлы сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез.**

1. ташкүмер, ташбака, шифаханә
2. башлык,ташчы, тимерче
3. ата-ана, ара-тирә, бала-чага
4. кибетче, укучы, бакчачы

**А15. 3 зат, күплек сандагы фигыльләрдән торган рәтне билгеләгез.**

1. укыйм, язам, уйныйм
2. укыйлар, язалар, уйныйлар
3. укыйсың, барасың, язасың
4. укыйбыз, язабыз, уйныйбыз

**А16. Киләчәк заман хикәя фигыльләргә ялгана торган кушымчаны билгеләгез.**

1. –а, –ә; –ый,–и
2. –ган–гән;–кан–кән
3. –ачак,–әчәк;–ячак,–ячәк
4. –ды,–де;–ты,–те

**А17. Күплек санда, төшем килешендә килгән исемне табыгыз.**

1. китаптан
2. балаларны
3. мәктәпнең
4. укытучыбызның

**А18. Дөрес язылышны табыгыз.**

1. ике йөз уналты
2. ике йөз ун алты
3. икейөз уналты
4. ике йөзуналты

**А19. Фигыльләрнең төркемчәсен билгеләгез.**

*тырышты, эшләгән, күрдек*

1. үткән заман хикәя фигыль
2. киләчәк заман хикәя фигыль
3. хәзерге заман хикәя фигыль
4. шарт фигыль

**А20. Күплек сан кушымчаларының дөрес ялганмау очрагын билгеләгез.**

1. авыллар,шәһәрләр,елгалар
2. хайваннар,җәнлекләр,кошлар
3. урманнар,күлләр,елгалар
4. сулар,комнар,ташлар

## 2 өлеш (В)

***Әлеге өлештәге биремнәрне, тәкъдим ителгән текст ярдәмендә үтәгәндә, җавапларыгызны җавап бланкында В1-В6 саннарының уң ягына беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга ярамый.***

*(1) Көзне инде җәнлекләр дә сизә. (2) Тиеннәр кышка әзерләнәләр, кызгылт йоннарын коялар, аны көлсуга алыштыру ягын карыйлар. (3) Күп итеп запас ясыйлар. (4) Чикләвек җыялар, начар чикләвекләрне алып та тормыйлар. (5) Имән чикләвеген дә кире какмыйлар. (6) Яннарында кеп-кечкенә балалары мәш килә.* *(Гарәфи Хәсәновтан)*

**В1.** Бишенче җөмләдәге калын әйтелешле сүзне языгыз.

**В2.** Текстан рус теленнән кергән алынма сүзне языгыз.

**В3.** Сыйфат булган җөмләләрнең санын күрсәтегез.

**В4.** Икенче җөмләнең иясен табыгыз һәм юнәлеш килешенә куеп языгыз.

**В5.** Беренче җөмләнең әйтү максаты буенча төрен билгеләгез.

**В6.** *Кеп-кечкенә* сүзенең ясалышы ягыннан төрен билгеләгез.